**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет Карамалинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Центральная, д. 8, село Карамалы, Азнакаевского муниципального района, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитеты**

Үзәк урам, 8, Карамалы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» август 2017 ел № 9

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең чыгым йөкләмәләре реестрын алып бару тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 87 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең чыгым йөкләмәләре реестрын алып баруның кушымта итеп бирелә торган кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитетына Карамалы авыл җирлегенең чыгым йөкләмәләре реестрын төзүне һәм аны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тапшыруны тәэмин итәргә.

3 Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru, «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык Ногманов А.Р.